РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

08 декабрь 2021 ел Олы Кайбыч ав. №87

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре Советларының Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетына авыл җирлекләренең Башкарма комитетлары тарафыннан төзекләндерү өлкәсендә җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында түбәндәге тәкъдимнәрен кабул итәргә:

- тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын килештерү буенча;
- җир эшләрен җитештерүгә рөхсәт бирү буенча.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы авыл җирлекләренең Башкарма комитетлары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://kaybici.tatarstan.ru/ веб - адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башлыгы урынбасары Р.Р. Хәялиевка йөкләргә.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль
районы Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин